| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ НОРМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ НОРМА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«29» апрель 2021 ел № 29

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәне раслау хакында**

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында"гы Федераль закон, "Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында"гы Федераль закон, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында"гы Татарстан Республикасы Законы, Балтач районы прокуратурасының 18.03.2021 ел, №02-08-02-2021 протесты нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы "Норма авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Норма авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәне, 1 нче кушымта нигезендә расларга.

2. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге Советының 18.12.2020 елнын № 19 «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәне раслау хакында» карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны pravo.tatarstan.ru «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» интернет-ресурсында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru), җирлекнең махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны авыл җирлеге башлыгы Шарипҗанов Радик Наиловичка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Норма авыл җирлеге башлыгы Р.Н. Шарипҗанов